**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2023 Балык Бистәсе штп. № 16пи

“2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту” муниципаль программасын раслау турында

Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм гражданнарның хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында” 10.11.2008 ел, №799 карарын үтәү йөзеннән, шулай ук хезмәтне саклау, хезмәтне куркынычсыз шартлар тудыру, җитештерү травматизмын кисәтү, кеше гомерен һәм сәламәтлеген саклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне координацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. “2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту” муниципаль программасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын Программаның заказчы – координаторы итеп билгеләргә.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль иминият фондының бүлекчәсенә, барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләргә, предприятиеләргә, оешмаларга программада каралган мөмкинлекләрне исәпкә алып, Программа чараларын финанслауны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту” муниципаль программасын раслау турында”26.12.2019 ел, №330пи карарының үз көчен югалтуын таныргa.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 2023 елның 25
гыйнварындагы 16 пи
номерлы карары белән
расланган

# “2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту” муниципаль программасы

## 1 бүлек. "2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту" муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту” муниципаль программасы (алга таба-программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләмә | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы |
| Программаның төп эшләүчеләре-координаторлары | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты;<br><br>Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Программаны башкаручылар | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты;<br><br>Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Программаның максатлары | 1.Район оешмаларында хезмәт шартларын һәм саклауны яхшырту.<br>2.Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру.<br>3. Куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирүче саклау һәм хезмәт шартлары өчен конституцион гарантияләрне тәэмин итү. |
| Программаның бурычлары | - эш бирүченең сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартларын булдыруны тәэмин итүче һәм стимуллаштыручы икътисадый һәм оештыру принципларын формалаштыру;<br>- производство травматизмы һәм профессиональ авырулар дәрәҗәсен киметү;<br>- хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләргә сәламәт һәм куркынычсыз эш шартлары булдыру ;<br>- хезмәтне саклауны мәгълүмат белән тәэмин итү һәм пропагандалау. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2023 – 2026 еллар |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау чыганаклары, күләмнәре | Программаны финанслауны барлык милек формаларындагы учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль иминият фонды бүлекчәсе средстволары (килешү буенча)хисабына башкару планлаштырыларыла<br><br>Җирле бюджеттан финанслау каралмаган.<br><br>Искәрмә: финанслау күләме фаразлана һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен көйләнергә тиеш. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - чараларны гамәлгә ашыру 2026 елга хезмәтне саклау таләпләрен бозу санын киметергә мөмкинлек бирәчәк;<br>- уңайсыз хезмәт шартларында эшләүчеләр саны киму;<br>- производство травматизмын һәм профессиональ авыруларны киметү;<br>- - хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- производстводагы бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү;<br>-производствода бәхетсезлек очракларыннан, производство-шартлы авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү. |
| Программаны тормышкаашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча Координация советы квартал саен һәм ел йомгаклары буенча программаның тормышка ашырылуын контрольдә тота. Билгеләнгән тәртиптә социаль-икътисадый вәзгыятьне исәпкә алып, Программа чараларын төгәлләштерү буенча тәкъдимнәр кертә. |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән чишү кирәклеген раслау

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы дәрәҗәсендә программаны эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгын билгеләүче мөһим фактор-бу проблеманың хезмәткә сәләтле халыкның тормыш сыйфатын күтәрү һәм сәламәтлеген саклау өлешендә социаль әһәмияткә ия булуы.

Программа бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны кисәтү һәм профилактикалау, хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирүче хезмәт шартларын тәэмин итү, эшләүчеләрне хокукый яклауны һәм хезмәтне саклауны дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Халыкның сәламәтлеген яхшыртуда һәм үлем санын киметүдә эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып эшләүче халыкның хезмәт шартларын

яхшырту һәм аны саклау, һөнәри куркынычны киметү, шулай ук эшләүчеләргә диспансеризация һәм профилактик тикшерүләр үткәрү тора.

## 3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан оешма һәм предприятиеләр хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту.

Программаның бурычлары:

- хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерүдә катнашу;
- заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү;
- хезмәтне саклауны мәгълүмат белән тәэмин итү һәм пропагандалау;
- эшләүче халыкка дәвалау-профилактик хезмәт күрсәтүне камилләштерү;
- производство травматизмын киметү.

## 4 бүлек. Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслауны район учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмалары, шулай ук Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль иминият фонды бүлекчәсе акчалары исәбеннән башкару планлаштырыла.

Җирле бюджеттан финанслау каралмаган.

## 5 бүлек.Программаның икътисади һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

1. Программа максатларга ирешүне тәэмин итә торган оештыру, методик, санитар-гигиена, укыту - пропаганда, пропаганда һәм башка чараларның бердәм комплексы буларак формалаштырылган һәм гамәлгә ашырыла.

2. Программаны эшләгәндә аны тормышка ашыру чыгымнарын оптимальләштерүгә, программа чараларын гамәлгә ашырганда социаль нәтиҗәгә ирешүгә бер үк вакытта ориентацияләүгә аерым игътибар бирелде.

3. Программаның тормышка ашырылуыннан көтелә:

1) Эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау проблемаларына күбрәк игътибарын җәлеп итү;

2) район оешмаларында хезмәтне саклау буенча белгечләр санын арттыру;

3) оешмаларда хезмәтне саклау белән идарә итүгә системалы характер бирү

4. Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча гомуми икътисади нәтиҗә күрсәтелә:

1) вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособиеләр түләүләрен киметү нәтиҗәсендә оешмалар керемнәрен, шулай ук бюджетка салым керемнәрен арттыруда;

2) Травматизм һәм авырулар белән бәйле эш вакытын югалту белән бәйле югалтулар санын киметүдә;

3) җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авыруларда килгән зыянны каплауга бәйле чыгымнарны киметүдә;

4) Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру нәтиҗәсендә табыш күләмен арттыруда;

5) хезмәт шартларын яхшырту хисабына кадрлар китүен киметүдә.

1. Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын башкаручы оешмалар шулай ук гамәлдәге закон таләпләрен бозган өчен штрафларны киметү хисабына икътисади нәтиҗә ала.

2. Программа үтәлешенең социаль нәтиҗәсе производство травматизмын һәм һөнәри авыруларны киметүдә, хезмәт куркынычсызлыгын һәм хезмәткәрләрнең социаль якланганлыгын арттыруда чагылачак.

3. Программаны тормышка ашыру халыкның, аеруча эшкә яраклылар яшендә, үлем дәрәҗәсен киметү өчен уңайлы шартлар тудыра.

Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № п/п | Программ чараларның атамасы | Программ чараларны башкаручы-лар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Шул исәптән сроклар буенча | | | | Финанслау чыганакларын күрсәтеп финанслау | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| Максат-район оешмаларында хезмәт һәм саклау шартларын яхшырту | | | | | | | | | | | |
| | Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторы | | Бәхетсезлек очраклары саны, бер. | 0 | 0 | 0 | 0 | | | | |
| Бурыч 1. Производство травматизмы дәрәҗәсенең , беренче чиратта, авыр һәм үлемгә китерә торганарының кимүе | | | | | | | | | | | |
| 1. | Хезмәтне саклау буенча Координация советы уздыру | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы | Уздырылган утырышлар саны, бер. . | 12 | 12 | 12 | 12 | финанслау таләп ителми | | | |
| 2. | Квартал саен хезмәт шартларының торышы һәм хезмәтне саклау һәм җитештерү травматизмын анализлау турында доклад әзерләү | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы | Докладлар саны, бер. | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | | |
| 3. | Ведомство карамагындагы мәгариф оешмаларында хезмәтне саклау торышын тикшерүне үткәрү | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы; «Татарстан | Уздырылган тикшерүләр саны, бер. | 12 | 12 | 12 | 12 | финанслау таләп ителми | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | | | | | | |
| 4. | Физик культура һәм спорт өлкәсендә ведомство карамагындагы учреждениеләрдә хезмәтне саклау торышын тикшерүне үткәрү | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы; "Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетның яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге " МКУ | Уздырылган тикшерүләр саны, бер. | 17 | 17 | 17 | 17 | финанслау таләп ителми |
| 5. | Район оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшлне иң яхшы оештыруга смотр - конкурс үткәрү | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы; | Конкурста катнашкан предприятиеләр саны, бер. | 50 | 50 | 50 | 50 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 нче бурыч. Хезмәткәрләргә хезмәт эшчәнлегендә сәламәт һәм куркынычсыз эш шартлары тудыру | | | | | | | | | |
| 1. | Эш урыннарын хезмәт һәм эргономика куркынычсызлыгын арттыру өчен җиһазлар белән, расланган нормалар нигезендә индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин итү | Район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары | Хезмәткәрләрне 100% саклау чаралары белән тәэмин итү | | | | | | Милекнең барлык формаларындагы район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары средстволары . |
| 2. | Районның барлык предприятиеләрендә, учреждениеләрендә, оешмаларында хезмәтне саклау буенча җаваплы хезмәткәрне боерык (күрсәтмә) белән, хезмәтне саклау буенча Координация советына боерыкны (күрсәтмәне) тапшырып билгеләргә. | Район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләре | | | | | | | финанслау таләп ителми . |
| 3. | Район предприятиеләрендә, оешмаларында, учреждениеләрендә хезмәткәрләрнең даими рәвештә медицина тикшерүләрен үткәрүне тәэмин итү . | Район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары | 100% хезмәткәрләр | | | | | | Милекнең барлык формаларындагы район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары средстволары . ТР Балык Бистәсе муниципаль районында Социаль иминиятләштерү фонды бүлекчәсе средстволары |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Оешмаларда хезмәт шартларының торышы һәм аны саклау турында район халкына хәбәр итү | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы;<br><br>Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты | Басылган мәкаләләр саны | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми |
| 3 нче бурыч. Заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү | | | | | | | | |
| 1 | 3 елга 1 тапкыр район предприятие-ләренең, учреждениеләренең, оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, җитәкчеләр урынбасарларын, хезмәтне саклау буенча җаваплы затларны укыту һәм Координация советына укыганнарның саны турында мәгълүмат тапшыру. | Район предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары | | | | | | Милекнең барлык формаларындагы район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары средстволары . |